**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**16.07.2018** **№ 1530**

**Опекага алынган затның саклык счетыннан файдалануга опекунга яки попечительгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында» 2009 елның 09 февралендәге 8-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2008 елның 20 мартындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Биектау муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Кушымтада бирелгән Опекага алынган затның саклык счетыннан файдалануга опекунга яки попечительгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын расларга.

2. Биектау муниципаль районы башкарма комитетының Опека һәм попечительлек хезмәтенә расланган административ регламент нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтүне гамәлгә ашырырга.

3. Үз көчен югалткан дип танырга:

3.1. 1.11 пункт. «Дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» Биектау муниципаль районы башкарма комитетының 2016 елның 06 маендагы 747 номерлы карарының Опекага алынган затның саклык счетыннан файдалануга опекунга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты 11 нче кушымтаны.

3.2. 1.11 пункт. Биектау муниципаль районы башкарма комитетының «Дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» Биектау

муниципаль районы башкарма комитетының 2016 елның 06 маендагы 747 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 2 мартындагы 539 карары, 11 нче кушымтасын.

4. Әлеге карар Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталының рәсми сайтында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарылырга һәм урнаштырылырга тиеш.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Р. Сабирҗановка йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф.Шәйдуллин

Кушымта
«РАСЛАНДЫ»
Татарстан Республикасы Биектау
муниципаль районы Башкарма
комитетының 2018 елның 16 июлендәге
1530 номерлы карары белән

**ОПЕКАГА АЛЫНГАН ЗАТНЫҢ САКЛЫК СЧЕТЫННАН ФАЙДАЛАНУГА ОПЕКУНГА ЯКИ ПОПЕЧИТЕЛЬГӘ РӨХСӘТ БИРҮ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ ХЕЗМӘТЕ КҮРСӘТҮНЕҢ АДМИНИСТРАТИВ РЕГЛАМЕНТЫ**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Регламент Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан опекага алынган затның саклык счетыннан файдалануга опекунга яки попечительгә рөхсәт бирү буенча рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең (алга таба – хезмәт күрсәтү) стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Дәүләт хезмәтен алучылар: физик затлар (опекуннар).

1.3. Дәүләт хезмәте гариза бирүченең яшәү урыны буенча «Биектау муниципаль районы башкарма комитеты» МКУның опека һәм попечительлек хезмәте тарафыннан күрсәтелә.

1.3.1. Опека һәм попечительлек хезмәтенең урнашкан урыны: ТР, Биектау т/юл ст. п., Мәктәп ур., 29й, 6 каб.

Опека һәм попечительлек органының кабул итү графигы: дүшәмбе 8.00 дән 12.00 гә кадәр, сишәмбе 13.00 дән 16.00 гә кадәр, шимбә, якшәмбе - ял көннәре, төшке аш 12.00 дән 13.00 гә кадәр.

Килү җәмәгать транспорты белән «Биектау ст.» тукталышына кадәр.

Керү шәхесне таныклаучы документлар буенча.

1.3.2. Белешмә телефоны: (843)6523269

1.3.3. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (алга таба – «Интернет» челтәре) “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты” МКУ рәсми сайтының адресы: (http:// www.//vysokaya-gora.tatarstan.ru).

1.3.4. Дәүләт хезмәте турында мәгълүмат алынырга мөмкин:

1) мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү өчен «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты» МКУ биналарында урнашкан дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган дәүләт хезмәте турында мәгълүмат стендлары ярдәмендә;

2) «Интернет» челтәре аша:

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының рәсми сайтында (http://www.vysokaya-gora.tatarstan.ru).

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatar.ru/);

Бердәм дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында (http://www.gosuslugi.ru/);

3) опека һәм попечительлек органына телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яисә

телефон аша);

4) опека һәм попечительлек органына язмача мөрәҗәгать (шул исәптән электрон документ рәвешендә) иткәндә.

1.3.5. Дәүләт хезмәтен күрсәтү мәсьәләләре буенча мәгълүмат алынырга мөмкин:

1) Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы (шәһәр округы) мәгариф бүлегенең муниципаль психолог-педагогик хезмәте бинасында урнашкан дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү өчен дәүләт хезмәте турында мәгълүмат стендлары ярдәмендә;

2) «Интернет» челтәре аша муниципаль районның рәсми сайтында (http://www.vysokaya-gora.tatarstan.ru)/;

3) Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре порталында (http://uslugi.tatar.ru/);

4) Бердәм дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында (http://www.gosuslugi.ru/);

5) Башкарма комитетта;

Телдән мөрәҗәгать иткәндә - шәхсән яисә телефоннан;

Язмача мөрәҗәгать иткәндә (шул исәптән электрон документ рәвешендә) - кәгазьдә почта аша, электрон рәвештә электрон почта аша.

1.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәге норматив актлар нигезендә башкарыла:

- Россия Федерациясе Конституциясе (бөтенхалык тавыш бирүе белән 12.12.1993 кабул ителде) (алга таба - РФ Конституциясе) (РФ законнары җыентыгы, 26.01.2009, № 4, 445 ст.)

-1995 елның 29 декабрендәге 223-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Гаилә кодексы (алга таба – РФ Гаилә кодексы) ("РФ законнары җыентыгы", 01.01.1996, №1, 16ст.);

-1994 елның 30 ноябрендәге 51-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Гражданнар кодексы (алга таба - РФ ГК) ("РФ законнар җыентыгы", 05.12.1994, №32, 3301 ст.);

-“Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында”, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары Җыентыгы, 2010, № 31, 4179 ст.);

-«Психиатрия ярдәме һәм аны күрсәткәндә гражданнарның хокуклары гарантияләре турында» 1992 елның 02 июлендәге 3185-I номерлы Россия Федерациясе Законы (алга таба - 3185-I номерлы РФ Законы) («Россия Федерациясе халык депутатлары Советы һәм Югары Советы Җыелма басмасы», 20.08.1992, № 33, 1913 ст.);

-«Россия Федерациясендә гражданнарның сәламәтлеген саклау нигезләре турында» 2011 елның 21 ноябрендәге 323-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 323-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары Җыентыгы, 28.11.2011, № 48, 6724 ст.)

-«Өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга социаль хезмәт күрсәтү турында» 02.08.1995 номерлы 122-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 122-ФЗ номерлы Федераль закон) («Россия Федерациясе законнары Җыентыгы»,07.08.1995, № 32, 3198 ст.);

- Күчемсез милекне дәүләт теркәвенә алу турында 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - дәүләт теркәве турында ФЗ) («Россия Федерациясе законнары Җыентыгы»20.07.2015, N 29 (I өлеш), 4344 ст.)

-"Шәхси мәгълүматлар турында" 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 152-ФЗ номерлы Федераль закон) («Россия Федерациясе законнары Җыентыгы », 2006, № 31 (1өл), 3451 ст.)

-"Опека һәм попечительлек турында" 2008 елның 24 апрелендәге 48-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 48-ФЗ номерлы Федераль закон) («Россия Федерациясе законнары Җыентыгы»,28.04.2008, №17, 1755 ст.);

-«Татарстан Республикасында опека һәм попечительлек органнары эшчәнлеген оештыру турында» 2004 елның 27 февралендәге 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба - 8-ТРЗ номерлы ТР Законы) (Татарстан Республикасы, №43-44, 02.03.2004);

-“Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында” 2008 елның 20 мартындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (“Ватаным Татарстан” 2008 елның 22 мартындагы №54, “Татарстан Республикасы” 2008 елның 25 мартындагы №60-61, Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, N 3, март 2008 ел);

-Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында" 2010 елның 02 ноябрендәге 880 номерлы карары (алга таба - 880 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм күрсәтмәләре җыентыгы һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы, 08.12.2010, № 46, 2144 ст.);

-Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 июнендәге 245 номерлы карары белән «Өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга социаль хезмәт күрсәтү дәүләт стационар учреждениеләрендә социаль хезмәт күрсәтү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының (алга таба - 245 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары) һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы, 11.07.2007, № 25-26, 0916 ст.).

-Биектау муниципаль районы Советының 2015 елның 21 сентябрендәге 7 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Уставы (алга таба – Устав);

-Биектау муниципаль районы Советының 2017 елның 16 февралендәге 122 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУсе турындагы Нигезләмә (алга таба – БК турында Нигезләмә);

-Биектау районы Советының 2010 елның 22 декабрендәге 27 номерлы карары белән расланган Биектау муниципаль районы башкарма комитетының опека һәм

попечительлек хезмәте турындагы нигезләмә (алга таба - Опека һәм попечительлек хезмәте турындагы нигезләмә);

-Биектау муниципаль районы башкарма комитетының "Эчке тәртип кагыйдәләрен раслау турында" карары белән 30.12.2010 № 3338.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Стандартка таләпнең исеме | Стандарт таләбенең эчтәлеге | Дәүләт хезмәтен яки таләпне билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Хезмәт күрсәтүнең исеме | Опекунга яисә попечительгә опекага алынган затның саклык счетыннан файдаланугa рөхсәт бирү | 30.11.1994 РФ ГК (беренче өлеш);<br>24.04.2008 48-ФЗ номерлы Федераль з<br>12.01.2013 8-ТРЗ номерлы ТР Законы; |
| 2.2. Турыдан-туры хезмәт күрсәтүче орган атамасы | Гариза бирүченең яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының Опека һәм попечительлек хезмәте | 21.09.2015 №7 Устав,<br>12.01.2009 7-ТРЗ ТР Законы |
| 2.3. Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе тасвирламасы | Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының опекунга яисә попечительгә опекага алынучының саклык счетыннан файдаланугa рөхсәт бирү йә опекунга яисә попечительгә саклык счетыннан файдаланугa рөхсәт бирүдән баш тарту турында карары | 30.11.1994 РФ ГК (беренче өлеш);<br>24.04.2008 48-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>12.01.2013 8-ТРЗ номерлы ТР Законы; |
| 2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү срогы | Мөрәҗәгать итүчедән кирәкле барлык документларны алганнан соң 15 эш көне эчендә. Карарны әзерләү башка оешмаларга соратулар җибәрүне, йә өстәмә консультацияләр таләп итсә, Башкарма комитет җитәкчесе карары буенча мөрәҗәгатьне карау срогы 30 эш көненә кадәр озайтылырга мөмкин.<br>(Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турындагы карар 15 эш көне эчендә кабул ителә. Тиешле карар гариза бирүчегә почта аша җибәрелә, йә турыдан-туры кабул итү вакытында бирелә). | |
| 2.5. Хезмәт күрсәтү өчен законнар яисә башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле | 1. Опекун яисә попечительнең, опекага алынган кеше мәнфәгатьләрендә конкрет чыгымнарны күрсәтеп, опекага алынучының саклык счетыннан файдаланугa рөхсәт бирүгә гаризасы, акчаны куллану турында хисап бирү шарты белән | 30.11.1994 РФ ГК (беренче өлеш);<br>24.04.2008 48-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>12.01.2013 8-ТРЗ номерлы ТР |

| | | |
|---|---|---|
| документларның тулы исемлеге | (мөмкинлекләрдән чыгып - счетлар, чеклар күчермәләре) (1 нче кушымта);<br>2. Опека яисә попечительлек билгеләү һәм опекун яисә попечитель билгеләү турында хокукый акт (карар);<br>3. Гражданны хокукка сәләтсез яисә хокукка сәләте чикләнгән дип тану турында суд органы карары күчермәсе;<br>4. Опекага алынган затның саклык кенәгәсе күчермәсе.<br>Дәүләт хезмәтен алу өчен гариза бланкын мөрәҗәгать итүче опека органына шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон формасы Башкарма комитетның рәсми сайтында урнаштырылган.<br>Гариза һәм теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазь чыганакларда түбәндәге ысулларның берсе тарафыннан тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:<br>шәхсән (мөрәҗәгать итүче исеменнән ышанычнамә нигезендә эш итүче зат тарафыннан);<br>почта аша.<br>Гариза һәм документлар шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша, һәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең Бердәм порталы аша тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин. | Законы; |
| 2.6. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен норматив хокукый актлар | Әлеге категориягә кертелергә мөмкин булган документларны бирү таләп ителми | |

| | | |
|---|---|---|
| нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге | | |
| 2.7. Норматив хокукый актларда каралган очракларда аларны килештерү хезмәт күрсәтү өчен таләп ителә торган һәм дәүләт хезмәте күрсәтүче башкарма хакимият органы тарафыннан гамәлгә ашырыла торган дәүләт хакимияте органнары һәм аларның структур бүлекчәләре исемлеге | Килештерү таләп ителми | |
| 2.8. Хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | 1. 1. Бирелгән документларның әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегенә туры килмәве.<br>2. Бирелә торган документларда алдан килештерелмәгән төзәтмәләр булуы. | |
| 2.9. Хезмәт күрсәтүне туктатып тору яки баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәтен туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.<br>Хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тора:<br>- дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен нигезләр булмау;<br>- мөрәҗәгать итүче тарафыннан әлеге Административ регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмау;<br>- опекага алынучының граждан һәм мөлкәти хокукларын кысу;<br>- мөрәҗәгать итүче тарафыннан бирелгән документларда ачыкланган дөрес булмаган яисә бозылган белешмәләр. | 30.11.1994 РФ ГК (беренче өлеш);<br>24.04.2008 48-ФЗ номерлы Федераль закон; |
| 2.10. Дәүләт хезмәтен | Хезмәт түләүсез нигездә күрсәтелә | |

| | | |
|---|---|---|
| күрсәтү өчен алына торган дәүләт пошлинасын яисә башка түләүне алу тәртибе, күләме һәм алу нигезләре | | |
| 2.11. Хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтү өчен түләүне алу тәртибе, күләме һәм алу нигезләре, мондый түләүнең күләмен исәпләү методикасы турында мәгълүматны да кертеп | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми. | 27.07.2010 210-ФЗ номерлы Федераль закон |
| 2.12. Хезмәт күрсәтү турында соратү биргәндә һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь срогы | Мөрәҗәгать итүчене кабул итүне (хезмәт күрсәтүне) көтүнең максималь срогы 15 минуттан артмаска тиеш.<br>Хезмәт алучыларның аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән. | 27.07.2010 210-ФЗ номерлы Федераль закон |
| 2.13. Хезмәт күрсәтү турында гариза бирүченең соратуын теркәү срогы | Гариза кергән көнне.<br>Электрон рәвештә кергән сорау ял (бәйрәм) көнендә ял көне алдыннан (бәйрәм) эш көнендә теркәлә. | 27.07.2010 210-ФЗ номерлы Федераль закон |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга таләпләр | Дәүләт хезмәтен күрсәтү янгынга каршы һәм янгын сүндерү системалары, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһаз, мәгълүмат стендлары булган биналарда гамәлгә ашырыла.<br>Инвалидларның дәүләт хезмәтен күрсәтү урынына каршылыксыз керүе тәэмин ителә (бинага уңайлы керү-чыгу һәм аның эчендә хәрәкәт итү).<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм | вазыйфаи регламентлар, вазыйфаи инструкцияләр |

| | | |
|---|---|---|
| | мультимедиа мәгълүматлары мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла. | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтеннән файдалану мөмкинлеге һәм аның сыйфаты күрсәткечләре | Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең һәркем өчен мөмкин булуы күрсәткечләре:<br>- бинаның җәмәгать транспорты йөри торган урында урнашуы;<br>- кирәкле санда белгечләр, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул итәлә торган биналар булу;<br>- мәгълүмати стендларда, «Интернет» челтәрендә http://vysokaya-gora.tatarstan.ru мәгълүмат ресурсларында, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләренең Бердәм порталында дәүләт хезмәтен күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу.<br>- инвалидларга башка затлар белән беррәттән хезмәт алырга комачаулаучы каршылыкларны үтүдә ярдәм күрсәтү<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең сыйфаты түбәндәгеләр булмау белән характерлана:<br>- мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан документлар кабул иткәндә һәм тапшырганда чиратлар;<br>- дәүләт хезмәтен күрсәтү срокларын бозу;<br>- дәүләт хезмәтен күрсәтүче хезмәткәрләрнең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата шикаять;<br>- дәүләт хезмәтен күрсәтүче хезмәткәрләрнең гариза бирүчеләргә карата әдәпсез, игътибарсыз мөнәсәбәтенә карата шикаятьләр.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында сорату биргәндә һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсен алганда дәүләт хезмәтен күрсәтүче вазыйфаи затның да, мөрәҗәгать итүченең дә бер тапкыр үзара хезмәттәшлеге күздә тотыла. Хезмәттәшлек дәвамлылыгы | 27.07.2010 210-ФЗ номерлы Федераль закон |

| | | |
|---|---|---|
| | регламент белән билгеләнә.<br>Дәүләт хезмәтләрен күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә (алга таба – КФҮ) дәүләт хезмәтен күрсәткәндә, КФҮнең ерак эш урыннарында консультация, документларны кабул итү һәм бирү белән КФҮ белгече шөгыльләнә.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү барышы турында мәгълүмат гариза бирүче тарафыннан Биектау муниципаль районы сайтында, дәүләт хезмәтләрен (функцияләрен) күрсәтүнең Бердәм порталында, КФҮ дә алынырга мөмкин» | |
| 2.16. Дәүләт хезмәтеннән файдалану мөмкинлеге һәм аның сыйфаты күрсәткечләре | Консультация Интернет-кабул итү бүлмәсе аша бирелә.<br>Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар граждан тарафыннан шәхсән үзе опека һәм попечительлек органына йә «Бердәм дәүләт хезмәтләре порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасын, региональ дәүләт хезмәтләре порталы (адресы: http://www.vysokaya-gora.tatarstan.ru) яисә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә опека һәм попечительлек органының рәсми сайтын кулланып, яисә опека һәм попечительлек органында үзара хезмәттәшлек турында килешүләр төзелгән күпфункцияле дәүләт хезмәтләре күрсәтү үзәкләренең вазыйфаи затлары аша, аннары рөхсәт алганда документларның төп нөсхәләрен күрсәтеп бирелергә мөмкин.<br>Опека һәм попечительлек органына шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта гражданин гариза биргәндә паспортын яисә аның шәхесен раслаучы башка документны күрсәтергә тиеш. | 27.07.2010 210-ФЗ номерлы Федераль закон |

## 3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре, шулай ук күп функцияле үзәкләрдә, дәүләти хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең читтән торып эшләү урыннарында административ процедураларны башкару үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәтен күрсәткәндә гамәлләр эзлеклелеген тасвирлау

3.1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:

-опекуннарга аларның опекун бурычларын үтәү мәсьәләләре буенча мәгълүмат бирү һәм консультацияләү; опекага алынучыларның саклык счетларыннан файдалануга рөхсәт бирү турында күрсәтмәләр бирү мәсьәләләре буенча опекуннарга һәм попечительләргә мәгълүмат бирү һәм консультация бирү;

- документлар, гаризаларны кабул итү, аларны теркәү;

- тапшырылган документларны кабул итү яисә кире кагу өчен нигезләр билгеләү өчен әлеге Административ регламентның таләпләренә туры килүенә тикшерү;

- дәүләт хезмәтен күрсәтү яисә күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул итү.

3.1.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелегенең блок-схемасы әлеге Административ регламентка 4 нче кушымтада күрсәтелгән.

3.2. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының опека һәм попечительлек бүлегенә яшәү урыны буенча опекун яисә попечительнең консультация алу өчен мөрәҗәгать итүе административ процедураны башлау өчен нигез булып тора. Опекун яисә попечитель опека һәм попечительлек бүлеге белгеченә паспортын, ә Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда аның шәхесен раслаучы башка документны, шулай ук аны опекун яисә попечитель итеп билгеләү турындагы норматив хокукый актны йә опекун яисә попечитель таныклыгын күрсәтә.

3.2. Гражданнарга консультация бирү һәм мәгълүмат җиткерү өчен җаваплы бүлек белгече, мәгълүмат бирү һәм консультация процедуралары кысаларында:

- дәүләт хезмәтен күрсәтү шартларын һәм тәртибен җайга сала торган норматив хокукый актлар турында мәгълүмат бирә;

- опекунны яисә попечительне опекадагы затның саклык счетларыннан файдалануга рөхсәт бирү турындагы карар бирү мәсьәләләре буенча дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе белән таныштыра;

- опекадагы затның саклык счетларыннан файдалануга рөхсәт бирү турында карар бирү өчен кирәкле документлар исемлеге бирә;

-дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза язу формасы турында аңлата.

- дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гариза бланкын бирә һәм, кирәк булса, гариза бланкын тутыруда ярдәм итә.

Консультацияләү гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне үткәрелә.

Процедуралар нәтиҗәсе: тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм хезмәт алуның башка мәсьәләләре буенча консультацияләр.

Консультацияләү һәм мәгълүмат бирү буенча административ процедураларны башкаруның гомуми срогы - 30 минутка кадәр.

Гражданнарны консультацияләүне һәм мәгълүматлаштыруны гамәлгә ашыручы белгеч конфиденциаль мәгълүматларны исәпкә алып уздырылган консультациянең тулылыгы, грамоталылыгы һәм һәркем файдалана алырлык булуы өчен шәхсән җаваплы.

3.3. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан гариза һәм документларны тапшыру әлеге Административ регламентның 2.5 пунктында каралган документларны кабул итү буенча административ процедураны башкару өчен нигез булып тора.

Гаризалар һәм документлар кабул итү өчен җаваплы опека һәм попечительлек хезмәте белгече әлеге Административ регламентның 2.5 п. нигезендә барлык кирәкле документларның комплектлылыгын һәм булуын тикшерә, шул исәптән:

-гражданинның (опекун яки попечительнең) шәхесен билгели - шәхесне раслаучы документ, шулай ук опека билгеләү турында норматив-хокукый актны (яисә опекун таныклыгын) тикшерә;

- опекун биргән барлык кирәкле документларның булуын һәм билгеләнгән таләпләргә туры килүен тикшерә;

- документларны тутыру дөреслеген тикшерә;

- барлык документлар текстлары җентекләп язылган һәм карандаш белән үтәлмәгән булуын билгели;

-документларда ассызыклаулар, өстәп язулар, сызылган сүзләр һәм, алдан килешенмәгән төзәтүләр юк, шулай ук документларда аларның булуы эчтәлеген бертөрле аңлатырга мөмкинлек бирми торган җитди зарарланулар юклыгын;

- кергән документларны терки;

- муниципаль берәмлек Башкарма комитетының опекунлык комиссиясенә җибәрү өчен документлар пакетын төзи (әгәр булса).

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән документлар.

Гамәлләрне үтәүнең максималь вакыты-10 минут.

Документлар кабул итү өчен җаваплы белгеч, конфиденциаль мәгълүматларны исәпкә алып, документлар кабул итү процедураларын үтәүнең дөреслеге өчен шәхси җаваплылык тота.

Бүлек белгечләре опекадагы зат турында мәгълүматлар банкындагы булган конфиденциаль мәгълүматтан рөхсәт ителмәгән һәм (яисә) аны күрсәтелгән мәгълүматтан файдалану хокукы булмаган затларга тапшыруны булдырмый калуны тәэмин итәргә тиеш.

Хокукка сәләтсез затлар һәм хокукка сәләте чикләнгән затлар турындагы бүлектә булган конфиденциаль мәгълүматның сакланышын һәм яклануын тәэмин итү максатларында белгечләргә документларны һәм тышкы саклагычларны вакытлыча файдалануга тапшыру, шул исәптән опекага алынган кешеләр турында мәгълүматлар банкына турыдан-туры керү эшчәнлеге төре буенча рөхсәте булмаган белгечләргә тыела.

3.4. Кирәкле документларның булмавы, тапшырылган документларның Регламент таләпләренә туры килмәве, гаризада яисә бирелгән документларда булган белешмәләрнең туры килмәве, йә опекуннан яисә попечительдән документлар кабул иткәндә кирәкле белешмәләрнең гаризада булмавы фактлары билгеләгәндә,

документлар кабул итү өчен җаваплы хезмәткәр дәүләт хезмәте күрсәтү өчен ачыкланган каршылыклар исемлеген төзи һәм мөрәҗәгать итүчегә тапшырылган документлар белән бергә тапшыра.

Процедуралар нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә кайтарылган документлар.

Гамәлләрне үтәүнең максималь срогы 10 минут тәшкил итә.

3.4.1. Опекун яисә попечитель җитешмәгән яисә төзәтелгән, яисә тиешенчә рәсмиләштерелгән документларны тапшырырга риза булмаганда, йә аларны бирү мөмкин булмаганда, шулай ук баш тарту өчен башка нигезләр булганда, белгеч мөрәҗәгать итүче (опекун) адресына аларны бетерү буенча чаралар күрергә тәкъдим ителгән язма хәбәр әзерли һәм муниципаль берәмлек Башкарма комитеты җитәкчесенә имзага язма хәбәрне тапшыра.

Процедураларның нәтиҗәсе: хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат проекты.

Гамәлне үтәүнең максималь срогы - 1 эш көне.

3.4.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен киртәләр булу турында имзаланган язма хәбәр опекунга яисә попечительгә бирелә яисә почта аша җибәрелә.

Процедураларның нәтиҗәсе: җибәрелгән язма хәбәр.

Үтәүнең максималь срогы - тиешле карар кабул ителгәннән соң 3 эш көне.

3.5. Опека һәм попечительлек хезмәте белгече, Опека һәм попечительлек советына (әгәр булса) бирү өчен документлар пакетын формалаштыра.

Процедураларның нәтиҗәсе: Опека һәм попечительлек советына төзелгән һәм карауга юнәлдерелгән документлар пакеты.

Максималь башкару срогы - 1 эш көне.

3.5.1. Утырышта Опека һәм попечительлек советы опекунга яки попечительгә опекага алынган затның саклык счетыннан файдалануга рөхсәт бирү турындагы мәсьәләне карый. Опека һәм попечительлек советы утырышы документлар кергән саен, ләкин атнага бер тапкырдан ким түгел.

Опека һәм попечительлек советы утырышының нәтиҗәсе булып, беркетмә белән рәсмиләштерелә торган һәм Опека һәм попечительлек советы рәисе һәм әгъзалары тарафыннан имзалана торган карарны кабул итү.

Гамәлләрне башкаруның максималь вакыты 3 эш көне.

3.5.2. Опека һәм попечительлек буенча Совет чыгарган карарларның нәтиҗәләре буенча опека һәм попечительлек хезмәте белгече опека һәм попечительлек буенча муниципаль берәмлек Башкарма комитетының опекунга яки попечительгә опекага алынган затның саклык счетыннан файдалануга рөхсәт бирү турында карары проектын (2 нче кушымта) йә опекунга яки попечительгә опекага алынган затның саклык счетыннан файдалануга рөхсәт бирүдән баш тарту турында карар проектын әзерли. Әлеге эш буенча карарларның нәтиҗәләре һәм документлар пакеты опекадагы затның шәхси эшенә беркетелә.

Процедураларның нәтиҗәсе: Җитәкчегә имзага җибәрелгән опекунга яки попечительгә опекага алынган затның саклык счетыннан файдалануга рөхсәт бирү турында йә опекунга яки попечительгә опекага алынган затның саклык счетыннан файдалануга рөхсәт бирүдән баш тарту турында карар проекты.

Максималь башкару срогы - 1 эш көне.

3.5.3. «Биектау муниципаль районы башкарма комитеты» МКУ җитәкчесе опека һәм попечительлек советы бәяләмәсен карый һәм опекунга яки попечительгә

опекага алынган затның саклык счетыннан файдалануга рөхсәт бирү турында йә опекунга яки попечительгә опекага алынган затның саклык счетыннан файдалануга рөхсәт бирүдән баш тарту турындагы карарларга кул куя.

Процедураларның нәтиҗәсе: имзаланган Карар.

Гамәлнең максималь вакыты - 3 эш көне.

3.5.4. Имзаланган Карар нигезендә опекунга яисә попечительгә опекага алынучының саклык счетыннан файдалануга рөхсәт кәгазе әзерләнә һәм почта аша җибәрелә яисә опекунга яисә попечительгә шәхсән тапшырыла, күчермәсе - опекага алучының шәхси эшенә беркетелә

Процедураларның нәтиҗәсе: опека һәм попечительлек секторы белгече опекунга яисә попечительгә опекага алынучының саклык счетыннан файдалануга рөхсәт бирә.

Эшнең максималь вакыты - 3 эш көне дәвамында.

3.5.5. Опекун яки попечительгә опекага алынучының саклык счетыннан файдалануддан баш тарткан очракта, Карарның бер нөсхәсе почта аша җибәрелә яки тиешле карар кабул ителгәннән соң шәхсән тапшырыла, икенчесе - опекага алынучының шәхси эшенә теркәлә.

Процедураларның нәтиҗәсе: опекунга яисә попечительгә опекага алынучының саклык счетыннан файдалануга баш тарту турындагы карар.

Эшнең максималь вакыты - 3 эш көне дәвамында

3.6. Техник хатаны (язу, хәреф хатасы, грамматик яки арифметик хата) төзәтү (5 нче кушымта).

3.7 Дәүләт хезмәтләрен күрсәтүнең күпфункцияле үзәге аша, КФҮнең читтән торып эш урыны дәүләт хезмәтен күрсәтү (6 нчы кушымта).

## 4. Дәүләт хезмәтен күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формалары

4.1. Югарыдагы вазыйфаи затлар (дәүләт хакимияте органнары) тарафыннан дәүләт хезмәтен күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын тикшереп торуны турыдан-туры гамәлгә ашыралар:

Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры (алга таба - министр) 420111, Казан шәһәре, Островский ур., 11/6й.; телефон (843) 231-79-98, факс (843) 238-41-44;

сәламәтлек саклау министры урынбасары 420111, Казан ш., Островский ур., 11/6 й.; телефон (843) 231-79-38;

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Эшләр белән идарә итүнең гражданнарның хатлары һәм мөрәҗәгатьләре белән эшләү буенча секторның әйдәп баручы консультанты 420111, Казан шәһ., Островский ур., 11/6; телефон (843) 231-79-84.

Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын тикшереп тору дәүләт вәкаләтләрен башкару турында кирәкле документларны, хисапларны һәм мәгълүматны соратуны үз эченә ала, тикшерүләр уздыруны, мөрәҗәгать итүчеләрнең хокукларын бозуларны ачыклау һәм бетерү, компетенциясе чикләрендә вазыйфаи затларның карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләрне үз

эченә алган мөрәҗәгать итүчеләрнең мөрәҗәгатьләренә карарлар һәм җаваплар әзерләү.

Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча, мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылган очракта, шулай ук конфиденциаль белешмәләрне фаш иткән очракта, күрсәтелгән тикшерү нәтиҗәләре буенча, гаепле затларны Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка җәлеп итү өчен, мәгълүмат муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты җитәкчесенә җибәрелә.

Тикшерүләр планлы һәм планнан тыш булырга мөмкин.

Планлы тикшерүләр 3 елга 1 тапкырдан ешрак үткәрелмәскә мөмкин.

4.2. Административ процедураларда билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеген үтәүне, белгечләр тарафыннан карарлар кабул итүне, дәүләт хезмәтен күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын тикшереп тору, шулай ук конфиденциаль белешмәләрне фаш итмәүне тикшереп тору Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге башкарма комитетының опека һәм попечительлек бүлеге җитәкчесе һәм муниципаль берәмлек Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.3. Муниципаль район башкарма комитетының опека һәм попечительлек хезмәте белгечләренең шәхси җаваплылыгы законнар таләпләре нигезендә аларның вазыйфаи регламентларында беркетелә.

4.4. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты» МКУ җитәкчесе әлеге регламентның 3 бүлегендә күрсәтелгән административ гамәлләрне вакытында һәм (яисә) тиешенчә үтәмәгән өчен җаваплы.

4.5. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан Регламентның үтәлешен тикшереп тору Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына мөрәҗәгатьләр җибәрү юлы белән, шулай ук Регламентны үтәү барышында башкарыла торган (кабул ителгән) гамәлләргә (гамәл кылмауга) һәм карарларга карата югарырак дәүләт хакимияте органнарына мөрәҗәгатьләр җибәрү юлы белән гамәлгә ашырыла.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, муниципаль хезмәтне күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның яисә муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының йә дәүләт яисә муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, шулай ук дәүләт хезмәтләрен күрсәтү функцияләрен гамәлгә ашыручы оешмаларның яки аларның хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) гариза бирүче тарафыннан судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү предметы

5.1. Дәүләт хезмәтен алучылар дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы опека һәм попечительлек секторы хезмәткәрләренең гамәлләренә (гамәл кылмавына) Татарстан Республикасы муниципаль районы Башкарма комитетына судка кадәр шикаять белдерү хокукына ия.

Гариза бирүче шикаять белән мөрәҗәгать итә ала, шул исәптән түбәндәге очракларда:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында соратуны теркәү вакытын, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 15.1 статьясында күрсәтелгән соратуны бозу;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү срогын бозу. Әгәр шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.3 өлешендә билгеләнгән тәртиптә тиешле дәүләт хезмәтләре күрсәтү функциясе тулы күләмдә йөкләнгән булса, күрсәтелгән очракта күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) мөрәҗәгать итүче тарафыннан судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү мөмкин;

3) мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән каралмаган документларны яисә мәгълүматны яисә гамәлләр башкаруны таләп итү;

4) мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән каралган документларны кабул итүдән баш тарту;

5) федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Россия Федерациясе субъектларының законнары һәм башка норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән баш тарту нигезләре каралмаган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту. Әгәр шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.3 өлешендә билгеләнгән тәртиптә тиешле дәүләт хезмәтләре күрсәтү функциясе тулы күләмдә йөкләнгән булса, күрсәтелгән очракта күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) мөрәҗәгать итүче тарафыннан судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү мөмкин;

6) дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән каралмаган түләүне таләп итү;

7) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның яисә дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә күрсәтелгән оешмаларның яисә аларның хезмәткәренең дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда басма хаталарны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуы яисә мондый төзәтмәләрнең билгеләнгән вакытын бозуы. Әгәр шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.3 өлешендә билгеләнгән тәртиптә тиешле дәүләт хезмәтләре күрсәтү функциясе тулы күләмдә йөкләнгән булса, күрсәтелгән очракта күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл

кылмавына) мөрәҗәгать итүче тарафыннан судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү мөмкин;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү срогын яки тәртибен бозу;

9) федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Россия Федерациясе субъектларының законнары һәм башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән туктатып тору нигезләре каралмаган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору. Әгәр шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.3 өлешендә билгеләнгән тәртиптә тиешле дәүләт хезмәтләре күрсәтү функциясе тулы күләмдә йөкләнгән булса, күрсәтелгән очракта күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) мөрәҗәгать итүче тарафыннан судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү мөмкин;

5.2. Шикаять язмача кәгазьдә яки электрон формада тапшырыла.

Шикаятьне почта аша, күпфункцияле үзәк аша, "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, Биектау муниципаль районының рәсми сайтыннан (http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/) һәм Татарстан Республикасының Бердәм дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatar.ru/), Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) Бердәм порталыннан (http://www.gosuslugi.ru/) файдаланып, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул итәргә мөмкин.

5.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органга, күпфункцияле үзәккә, күпфункцияле үзәкнең оештыручысына, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган оешмаларга яисә югары органга (ул булган очракта) кергән шикаять аны теркәгәннән соң унбиш эш көне эчендә каралырга тиеш, ә дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәкнең оештыручысының, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган оешмаларның мөрәҗәгать итүченең документларын кабул итүдән яисә җибәрелгән басма хаталарны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуына яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакытын бозуга карата шикаять белдергән очракта - аны теркәгән көннән алып биш эш көне эчендә.

5.4. Шикаять түбәндәгеләрне үз эченә алырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять белдерелә торган дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яисә муниципаль хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, аның җитәкчесенең һәм (яисә) хезмәткәренең, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә күрсәтелгән оешмаларның, аларның җитәкчесенең һәм (яисә) хезмәткәрләренең исеме;

2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), яшәү урыны турында мәгълүмат яисә мөрәҗәгать итүче – юридик затның атамасы, урнашу урыны турында мәгълүмат, шулай ук мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә тиешле элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазифаи затының, яки муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә күрсәтелгән оешмаларның яисә аларның хезмәткәренең шикаять ителүче карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында белешмәләр;

4) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазифаи затының, яки муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә күрсәтелгән оешмаларның яисә аларның хезмәткәренең карары һәм гамәле (гамәл кылмавы) белән килешмәвенә нигез булган дәлилләр. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан аның дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яисә аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.5. Шикаятьтә тасвирланган хәлләрне раслаучы документларның күчермәләре шикаятькә кушымта итеп бирелергә мөмкин. Бу очракта шикаятьтә аңа кушып бирелә торган документлар исемлеге китерелә.

5.6. Шикаять аны тапшырган дәүләт хезмәтен алучы тарафыннан имзалана.

5.7. Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаятьне канәгатьләндерү, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталар һәм ялгышларны төзәтү, гариза бирүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән каралмаган акчаларны кире кайтару формасында;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

5.7 пунктта күрсәтелгән карарны кабул иткән көннең икенче көненнән дә соңга калмыйча, гариза бирүчегә язма рәвештә һәм гариза бирүче теләге буенча электрон формада шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында дәлилле җавап җибәрелә.

5.8. Шикаятьне карап тикшерү барышында яисә карап тикшерү нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу составы билгеләре яки җинаять билгеләре ачыкланганда, шикаятьне карап тикшерү буенча вәкаләтләр бирелгән вазыйфаи зат булган материалларны «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 11.2 статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән нигезләрдә кичекмәстән прокуратура органнарына юллый.

Яшәү урыны алмашынуга бәйле рәвештә, опекунга опекага алынган затны яшәү урыны буенча теркәү исәбеннән төшерү өчен рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы
Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты
җитәкчесе
_______________________________
(Җитәкченең фамилиясе, инициаллары)
_______________________________________
(гариза бирүченең Ф.И.А., туган көне, яшәү урыны)
_______________________________
_______________________________
_______________________________
(өй, мобиль телефон)
_______________________________
(паспорт мәгълүматы)

**Гариза**

Түбәндә күрсәтелгән суммада акча белән эш итүгә (счеттан төшерүгә) рөхсәт бирүегезне сорыйм
_____________________________________________________________________________________
(сүз белән)
опекуны (попечителе) булып мин торган (кирәклесен ассызыкларга) хокукка сәләтсез (хокукка сәләте чикләнгән граждан) түбәндәге затның,
_________________________________________________________________________________
(хокукка сәләтсез ,хокукка сәләте чикләнгән гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме)
Күрсәтелгән акчалар белән эш итү түбәндәге максатлар өчен кирәк:____________________
_____________________________________________________________________________________
_____________________________________________________________________________________
_____________________________________________________________________________________
_____________________________________________________________________________________

Дата "__" __________ ____ ел Имза ________________________
Теркәлде "__" ___________ ____ ел № _____

________________________ ____________ __________________
(белгечнең вазыйфасы) (имза) (тулы имза)

Яшәү урыны алмашынуга бәйле рәвештә, опекунга опекага алынган затны яшәү урыны буенча теркәү исәбеннән төшерү өчен рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта

**КАРАР**

№ _____ __________

**Опекага алынган затның счетыннан файдалану турында**

Опекун, попечитель ________________________________________________ гаризасын карап,
(фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган көне)
_________елда туган, түбәндәге адрес буенча яшәүче: __________________________________________
____________________________________________________________________________________________
(даими яшәү урыны адресы - өлкә, шәһәр, район, урам, йорт №, фатир №)
опекуны (попечителе) булып мин торган (кирәклесен ассызыкларга) хокукка сәләтсез (хокукка сәләте чикләнгән граждан) түбәндәге затның акчалары белән эш итүгә
____________________________________________________________________________________
(хокукка сәләтсез, хокукка сәләте чикләнгән гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме)
______________елда туган,
____________________ судының ___________________ карары белән хокукка сәләтсез, хокукка сәләте
(суд исеме) (суд карарының датасы)
чикләнгән дип танылган

Россия Федерациясе Граждан кодексының 37 статьясы нигезендә һәм опека һәм попечительлек Советының "__" ___ ____, ел бәяләмәсе нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Опекун, попечитель____________________________________________________________
(опекун, попечительнең фамилиясе, исеме, атасының исеме)
_____________________________________________ суммадагы
(сүз белән)
хокукка сәләтсез затның (хокукка сәләте чикләнгән гражданның) (кирәкмәгәнен сызарга)
___________________________________________________________________________________________
(хокукка сәләтсез, хокукка сәләте чикләнгән гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме)
__________________________________________________________________ максатларында акчасы белән эш итүгә рөхсәт бирергә.
2. Опекунга ай саен опекага алынучы (тәрбиягә алынган) затның пенсиясен һәм башка социаль түләүләрен алырга рөхсәт итәргә ________________________________________________________,
(опекага алынучы (тәрбиягә алынган) затның ФИА)
________елда туган ______________________________________________________________
(илтеп җиткерү оешмасының исеме - почта бүлекчәсе, башка оешма, кредит учреждениесе исеме, опека алынучының кертеме буенча счеты)
_____________________ срокка
(1 елга, әмма пенсия билгеләнгән вакыттан да артык түгел)
3. Опекун, попечительгә ел саен агымдагы елның 1 февраленнән дә соңга калмыйча опека һәм попечительлек секторына опекага алынган затның мөлкәтен саклау, аннан файдалану һәм кулланутурында узган ел өчен хисап бирергә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары _____________________________________ йөкләргә.
(фамилиясе, инициаллары)

Җитәкче ______________/ _____________________________
(имза) (фамилиясе, инициаллары)

М.У.

Яшәү урыны алмашынуга бәйле рәвештә, опекунга опекага алынган затны яшәү урыны буенча теркәү исәбеннән төшерү өчен рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 3 нче кушымта

**Пенсияләр һәм башка социаль түләүләр суммасын алуга**
**Р Ө Х С Ә Т**

Опекун, попечитель ________________________________________________итеп билгеләнгән
(документ исеме, датасы, һәм номеры)
_________________________________________________________________________
(опекун, попечительнең ФИА)
опекага алынган затның ай саен пенсиясен һәм башка социаль түләүләрен алырга
__________________________________________________________________________________________,
(опекага алынучы (тәрбиягә алынган) затның ФИА)
________елда туган ___________________________________________________________________
(илтеп җиткерү оешмасының исеме - почта бүлекчәсе, башка оешма, кредит учреждениесе исеме
_____________________________________________________________________________________________
опека алынучының кертеме буенча счет номеры)

Рөхсәтнең гамәлдә булу срогы ______________________________________
(1 елга, әмма пенсия билгеләнгән вакыттан да артык түгел)

Опека һәм попечительлек буенча сектор мөдире _____________ ( ____________)
(имза) (ФИА)

М.У.

Яшәү урыны алмашынуга бәйле рәвештә, опекунга опекага алынган затны яшәү урыны буенча теркәү исәбеннән төшерү өчен рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 4 нче кушымта

**Тәрбияләнүчеләрне стационар хезмәт күрсәтүгә психоневрология тибындагы интернат-йортларга җибәрү турында карарлар бирү буенча Татарстан Республикасы Биектау районы Башкарма комитеты тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүнең БЛОК-СХЕМАСЫ**

Тәрбияләнүчеләрне психоневрология тибындагы интернат-йортларга стационар социаль хезмәт күрсәтүгә җибәрү турында карар бирү мәсьәләләре буенча гражданнарга мәгълүмат бирү һәм консультацияләү

//

Документларны кабул итү һәм теркәү

//

Бирелгән документларга, аларда булган белешмәләрнең тулылыгын тикшерү үткәрү

//

Тәрбияләнүченең (хокуктан файдалануга сәләтсез затның) мөлкәте турында Бердәм дәүләт хокуклар реестрыннан өземтә бирү турында сорату җибәрү

//

Ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша кергән сорату нигезендә белешмәләр бирүче соратып алына торган документларны (белешмәләрне) тапшыра яисә бирүдән баш тарта.

//

Дәүләт хезмәтен күрсәтүгә йә баш тартуга нигезләрен билгеләү

// \\

Опека һәм попечительлек советы утырышының тәрбияләнүчеләрне психоневрологик типтагы интернат-йортларга җибәрү турындагы карарын бирү турындагы беркетмәсеннән өземтә әзерләү

Опека һәм попечительлек советы утырышының тәрбияләнүчеләрне психоневрологик типтагы интернат-йортларга җибәрүдән баш тарту турындагы карарын бирү турындагы беркетмәсеннән өземтә әзерләү

// \\

Опека һәм попечительлек Советы утырышы беркетмәсеннән өземтә бирү

Яшәү урыны алмашынуга бәйле рәвештә, опекунга опекага алынган затны яшәү урыны буенча теркәү исәбеннән төшерү өчен рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 5 нче кушымта

ТР муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә

Техник хатаны төзәтү турында
гариза

Мин, ______________________________________________________________________________

*(фамилиясе, исеме, атасының исеме тулысынча күрсәтелә)*

Түбәндәге адрес буенча яшәүче__________________________________________________________

_________________________________________________________________________________

*(гариза бирүченең почта адресы, индексын күрсәтеп, телефоны, электрон адресы)*

_____________________________________________________________________________

*(мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклаган документ исеме, аның сериясе, номеры, бирелү датасы)*

_________________________________________________________________________________

*(документ биргән органның исеме)*

Балигъ булмаган (нар) исеменнән сатып алуның өстенлекле хокукыннан баш тартуга алдан рөхсәт бирү буенча карарда җибәрелгән
техник хатаны төзәтүне сорыйм ____________________________________________________

________ №__________
карар датасы карар номеры

Техник хатаны төзәтү турында мәгълүмат алуга риза

Дата: Имза:

Яшәү урыны алмашынуга бәйле рәвештә, опекунга опекага алынган затны яшәү урыны буенча теркәү исәбеннән төшерү өчен рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 6 нчы кушымта

Читтәге эш урыннарының исемлеге һәм документлар кабул итү графигы

| № | Читтәге эш урынының урнашкан урыны | Хезмәт күрсәтелә торган торак пунктлар | Кабул итү графигы |
| --- | --- | --- | --- |
| 1 | Биектау ав., Полк ур., 9 й | Биектау районы | Дүш-җом – 8:00-17:00<br>Шим- 8.00-13.00<br><br>Сиш-14.00-17.00 (консультация) |
| | | | |

## Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи затларның реквизитлары

### Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының опека һәм попечительлек хезмәте

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Опека һәм попечительлек хезмәтенең әйдәүче белгече Надиенко Л.М. | (8-84365) 2-32-69 | Liliya.Nadienko@tatar.ru |

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Биектау муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе Шәйдуллин Дамир Фәрит улы | 2-30-61 | biektau@tatar.ru |
| Социаль мәсьәләләр буенча җитәкче урынбасары Сабирҗанов Ринат Рәшит улы | 2-30-87 | Sabirzyanov.Rinat@tatar.ru |